РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
УРЮМСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЮМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 54-0-38, факс 54-0-38

**КАРАР**

**18 ноябрь 2019 ел** **№ 4**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Урюм авыл җирлегенең Пролей-Каша торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

2019 елның 30 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы «Урюм урта гомуми белем бирү мәктәбе» Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Пролей-Каша торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Пролей-Каша торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Россия Федерациясе

Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, ирektән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Пролей-Каша авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Пролей-Каша авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Урюм авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Урюм авыл җирлеге башлыгы** **Н.М. Краснов**